«Идегәй» дастанындагы кайбер мотивлар

Рухи дөнья мәдәниятендә дастаннар аерым урын алып торалар һәм безгә теге яки бу халыкның иң борынгы яшәү һәм фикерләү рәвешен җиткерүдә мөһим чыганакларның берсе. Халык хәтере үзенең иң борынгы йолаларын, гореф-гадәтләрен, ышануларын саклап калып, аларны хәзерге вакытка кадәр китергән. Һәм иң әһәмиятлесе — эпик дастан бер милләтнең генә түгел, ә бәлки бер халык булып оешкан күп кенә милләтләрнең үткәнен билгеле бер дәрәҗәдә чагылдыра. «Идегәй» дастанында да, татар халкының омтылышлары, холкы, гореф-гадәтләре сурәтләнүе белән бергә, башка төркиләрнең ышанулары, дәүләт тоту тәртипләре, гаиләкөнкүреш йолалары киң урын алган. Анда тасвирланган вакыйгалар бер-берләре белән тыгыз тарихи һәм мәдәни бәйләнештә яшәгән күп кенә төрки кабиләләрне үз эченә сыйдырган бер дәүләттә — Алтын Урдада (1241-1502) булуын онытмаска кирәк. Ләкин дастанны анализлау барышында татарлар белән бергә, кыпчак төркеменә кергән башкорт, нугай, кыргыз һәм казакъларның гореф-гадәтләренә һәм ышануларына да мөрәҗәгать итүне кирәк таптык: чөнки ярымкүчмә, ярымутрак хәят кичергән әлеге халыкларның мәдәнияте хаклы рәвештә Алтын Урда мәдәниятенең аерылгысыз бер өлеше булып исәпләнә[1].

Алтын Урда хөкемдарлары Чыңгыз нәселеннән булулары, аларның ассимиляцияләшүенә карамастан, монголларга хас үзенчәлекле гореф-гадәтләргә тугрылыклы калганнар. Шуңа күрә, безнең әлеге тикшеренүебездә, төркиләрнең гореф-гадәтләре белән бергә монголларның борынгы динен өйрәнгән француз галиме Жан Поль Руның хезмәте дә билгеле бер юнәлеш булып тора. Гомумән, бу ике халыкның бөтендөнья социаль, икътисади һәм мәдәни тормышында зур роль уйнаулары мәгълүм. Чөнки борынгы дәвердә алар белән аралашмыйча бик аз халык калгандыр[2]. Ләкин «Идегәй» дастанын тикшерү өчен монголларның һәм бөтен төрки халыкларның көнкүрешен, гореф-гадәтләрен генә түгел, ә бәлки, алар бу җирләргә килеп урнашканчы, биредә яшәгән скифларның һәм һуннарның, алай гына да түгел — бөтен алдынгы цивилизацияләрнең көндәлек тормышын, ышануларын, йолаларын да белү зарур.

«Идегәй» — мифология белән бәйләнешле бик сирәк һәм чынбарлыкка иң якын дастаннардан саналса да, анда мәҗүсилек чоры белән бәйле урыннар да еш очрый. Чөнки әлеге чор татарларның көнкүрешенә, тормыш фәлсәфәсенә дә зур йогынты ясаган. Ислам дине кабул ителгәннән соң мәҗүсилек белән бәйле хәрәкәтләр (күрәзәчелек, каргыш, табигать

көчләреннән ярдәм сорау һ. б.) кешеләрнең күңелләрендә сакланып килгән. Шуңа күрә «Идегәй» дастаны ислам диненең дәүләт тәртибенә һәм халык аңына ныклап урнашкан бер чорда барлыкка килгән булуына карамастан, аның каһарманнары еш кына «Аллаһым» диясе урында «Тәңрем» диләр. Бәлки моның сәбәбе, тәңречелекнең кешене табигатькә якынайтуы һәм тормышындагы төрле ышануларга, күрәзәлек, сихер кебек көчле тәэсирләргә шактый зур урын биргән ышану системасы булуындадыр? А. Инан язганча, «Чыңгыз хан тирәсендә тупланган төркы халыклар һәм монголлар, башка диннәрнең тәэсирендә калып, мәҗүсилектән шактый ераклашканнар. Ләкин, моңа карамастан, монгол явы Урта Азия һәм Идел буе мөселманнарында инде югалып барган мәҗүсилек кыйпылчыкларының яңадан җанланып китүенә сәбәпче булды. Шуңа күрә монгол явыннан соң язылган чыганакларда мәҗүсилек белән бәйле мәгълүматлар күбрәк»[3]. Тарих безгә монголларның барлык диннәргә дә хөрмәт белән караулары турында сөйли. Чыңгыздан килгән гадәт буенча Алтын Урда дәүләтендә дә диннәр иреге сакланган була.

Гореф-гадәтләр — барлык халыкларга, милләтләргә хас уртак күренеш. Аларга карап һәр милләтнең тарихын, рухи халәтен, менталитетын танырга өйрәнәбез. Бер дәүләт эчендә, хәтта күрше дәүләтләрдә яшәгән халыклар, бер-берсенә, әлбәттә, тәэсир итми калмаганнар. Ә инде ышануларга килгәндә, аларны — һәр халыкның тарихы, мәдәнияте, асылы, милли барлыгы дип санарга хакыбыз бар. Шул рәвешле, «Идегәй» дастанында, хәзерге вакытта бик үк аңлашылып бетмәгән гореф-гадәтләр һәм тормыш-көнкүреш белән бәйле детальләр дә очрамый түгел. Аларның кыпчак төркеменә кертелгән һәм XX гасырга кадәр күчмә тормыш белән яшәүләрен дәвам иткән башка төркы халыкларның (казакъ, кыргыз) көндәлек тормышына хас булып, аларда бүгенгәчә сакланып килүе безгә кызыклы гына тикшеренү ясарга мөмкинлек бирә.

Бүгенге төркы дөньяның нигез ташы булып саналган уртак гореф-гадәтләр, ышанулар арасындагы бәйләнешкә килгәндә исә, ул тагын бер мәртәбә төркы халыкларның тарихи берлеген һәм бөтенлеген күрсәтеп торучы факторларның берсе булып кала.

Гаилә-көнкүреш йолаларының чагылышы.

Халык авыз иҗатында гаилә-көнкүреш йолалары өч төргә бүленә: өйләнү-никах, бала тууы һәм вафат булу. Алар төрле гореф-гадәтләр һәм ышанулар белән тыгыз үрелгән. Гаиләдә үткәрелә торган йолалар, кешене төрле кара көчләрдән саклап калу юлларын күрсәтү белән бергә, кеше кадерен аңларга да ярдәм итәләр. Барлык төркы дастаннарда әһәмиятле урын алып торган әлеге йолалар, ислам дине кабул ителгәнче, бабаларыбыз яшәгән мәҗүсилек дәверенең эзләрен дә саклыйлар.

I. Өйләнү.

Гаилә кору, аны яман кешеләрдән, дошманнардан саклау — каһарманлык дастаннарына хас төп темаларның берсе.

«Идегәй» дастанында беренче мәртәбә туй төп каһарманның өйләнүе белән бәйле рәвештә телгә алына:

Бер бите айдай балкыган,
Бер бите көндәй салкыган,
Болгардаен болкыган,
Җофардаен аңкыган
Айтулы ару кыз икән —
Туеннан туен кылдырып,
Сөяренә аны алды.
(35)[4]

Идегәйнең Идел-йортка карата әйткән сүзләре:

Атам кияү булган йорт —
Иелеп тәзем кылган йорт;
Анам килен булган йорт —
Иелеп сәлам әйткән йорт.
(132)

I. 1. Иелеп тәзем кылган йорт.

Туйның иң әһәмиятле өлеше — кызның килен булып кияү өенә төшүедер, мөгаен. Бу уңайдан, бик борынгы чорлардан бирле, төркы халыкларга хас булган «гаилә учагы» төшенчәсен карап үтү зарур. Өйдә янган учак — ул гаилә символы булган. Өйләнү, никах белән бәйле йолалар да нәкъ менә учак, ут культыннан туган ышанулар нигезендә башкарылганнар. Учак культы дастаннарга да үтеп кергән һәм аларда яхшы гына җирлек тапкан. Әүвәл Алтай халкының героик «Алып Манас» эпосына игътибарны юнәлтик:

Ал Каган бар иде,
Аның ир йөзе күрмәгән,
Ир кулы тимәгән
Иркә-Каракчы исемле кызы бар иде.
Учагымны аның белән бергә яктым[5].

Кияү өенә килгән киленнең беренче эше учакка хөрмәт күрсәтү булган. А. Инан язганча, «яңа килен булып төшкән кызларның

ата чатырының учагындагы утка иелеп сәлам бирүләрен» үзе дә күп мәртәбә күргән. «Казакълар моңа «тәҗим» диләр, һәрхәлдә гарәпчәдән «тәгъзыйм» сүзенең бозылып әйтелүе булса кирәк», дип өсти галим[6]. Мәсәлән, «Манас» дастанында Ак-Сайкал Хатын, никахтан соң иң беренче эше итеп, иелеп гаилә учагына сәлам бирә. Алтай халкында кыз ярәшелгән егетенең өенә килгәч, шулай ук беренче чиратта, җиргә кадәр иелеп, учакка хөрмәт күрсәткән. Аңа «учагың беркайчан да сүнмәсен!» дип теләк теләгәннәр[7]. Димәк, килен булып төшкәнче үк кызлар учакка үзләренең хөрмәтләрен күрсәтергә тиеш булганнар. Мондый фактлар барлык төрки халыклар өчен дә хас булган. Ләкин әлеге йоланың хәзергә кадәр нәкъ менә алтайлыларда сакланып килүе — аларның цивилизация йогынтысыннан ерак калулары нәтиҗәсе буларак кабул ителергә мөмкин. Македониядә яшәгән төрекләрдә дә килен булып төшкән кызны иң элек учак янына китерәләр һәм ул учакка сәлам бирергә тиеш.

«Идегәй» дастанында исә Идегәйнең килен булып төшкән әнисе генә түгел, кияү булган атасы да, учак алдына килеп, иелеп тәзем кыла. Мәсәлән, казакъларда һәм кыргызларда кияү кеше әле бүген дә кыз өенә кергәч, кызның атасына, анасына һәм бабаларының рухына өч мәртәбә иелеп хөрмәтен күрсәтергә тиеш. Ләкин дастанда «иелеп тәзем кылган йорт» дигән юллардагы «тәзем» сүзе бу күренешне учак культы белән кararга мөмкинлек бирә.

I. 2. Иелеп аяк алу.

«Идегәй» дастанында килен булып төшкән Йәникәнең, тезен чүгеп, аяк (касә) белән бал (эчемлек) алып эчүе әйтелә. Ул — киленнең мул, сыйлы тормышта яшәвен теләү белән бәйле. Казакъларда хәзер дә кияү кеше, кызны алырга килгәч, анасы аңа бер касә кымыз сузып, матур теләкләр әйтә[8]. Бу гадәт кыргызларда да бар. Ә татарларда исә, ул кияү кешегә түгел, киленгә юнәлтелгән.

I. 3. Бөркәнчек ябу.

Яшь киленгә ак бөркәнчек ябу йоласы турында дастанда болай әйтелә: «Ак бөркәнчек кигән йорт». Ф. Баязитова язганча, Әстерхан татарларында XX гасырның ахырына кадәр «биткүрәм туй» йоласы үткәрелгән, ягъни анда киленнең бөркәнчеге ачылган[9]. Казакълар бу йолага «бет ашар» («бит ачар») диләр. Нугайларда туйның икенче көне бүген дә «бет ашар туй» («бит ачу туе») дип йөртелә. Төрекмәннәр бу йола башкарылган көнне «дувак гюню» дип атыйлар. Киленнең бөркәнчеген ачу — күп кенә төрки халыкларның туй йоласы эчендә урын алган уртак гадәт. Элек килен, кияү йортына килгәндә йөзенә ак (яисә ал) бөркәнчек капларга тиеш булган. Галимнәр фикеренчә, бу йола — киленне явыз, кара көчләрдән, күз тиюдән саклау чарасы һәм, әлбәттә, килен булып төшкән кызның саф-лыгына да ишарә итә[10]. Алай гына да түгел: бөркәнчек салдыру — кызның моннан соң башка бер нәселгә күчүен дә белдергән[11]. Бу хакта танылган тюрколог С. Абрамзон болай дип яза: «Кыргыз кызлары, беркайчан да алтай кызлары кебек йөзләрен каплап йөрмәгәннәр. Ләкин килен булып төшәсе йортка, авылга беренче мәртәбә килүләрендә битләрен «бөркәнчек» исеме бирелгән ак тукыма белән каплап килгәннәр»[12]. Төрекләрдә әле бүген дә кыз кияү өенә башына ал яисә кызыл төстәге бөркәнчек каплап төшә. Ләкин кыпчакларда (татарларда, кыргызларда, казакъларда), угызлардан аермалы буларак, бөркәнчек ак төстә булган.

I. 4. Каплы камка ерту.

«Идегәй» дастанында безгә бик үк аңлашылып бетмәгән мондый юллар да бар:

Каплы камка ерткан йорт.

«Камка» сүзе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «алтын-көмеш белән аралаштырып суккан тукыма»[13], дип бирелә. Хәтта татарларда «кием кисәң камка ки, эче тузмый, төсе уңмый», дигән бер әйтем дә бар һәм аның кыйммәтле һәм чыдам тукыма булгандыр дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Дастанда, алда күрсәтеп үткән юлларга, «биредә гадәт-йола турында сүз бара» дип искәрмә бирелә. Нинди гадәт-йола турында сүз бара соң «Идегәй»дә? Әлбәттә, бу гадәт-йола туй вакытында үткәрелгәндер, чөнки сүзлектә «ертыш» сүзенең аңлатмасына карасак, анда: «Кычкырышып-шаярышып туй бүләге итеп бирелгән тукыманы ерту йоласы» диелгән һәм мисал итеп татар халык мәкале дә китерелгән:

Агай-эненең тартышы —
— Туй бүләге ертышы[14].

Әйтелгән чыганакта бу сүзнең диалект үзенчәлеге булуы турында да язылылган.

Башкортларның туй йолаларына игътибар итсәк, аларда килен белән кияүне ялгыз калдырыр алдыннан үткәрелә торган «йыртыш басыу» (бусагадан атлап, тукыма өстенә басу) яисә «йыртыш йыртыу» (тукыма ерту) йоласы бар. Кияү егет, кыз яны-

на кергәнче, бусагада ике ягыннан ике җиңгәсе тотып торган кызыл тукыманы аягы белән ертып, һәр ике кисәген җиңгәләренә бирергә тиеш. Тукыманы ерту — яңа статуска күчүне, балачактан балигълыкка керүне белдергән. «Идегәй» дастанында да сүз нәкъ менә бу йола-гадәт турында баргандыр.

Казакъ туйларында да кайната өенә җибәрелгән бүләкләр арасына «жыртыш» дип аталган тукымалар куела. Татар халкында да элек кызларның бирнәсенә килен бүләге итеп өләшү өчен тукыма кисәкләре куелган.

II. Бала туу.

Гаиләдә бала туу — кеше тормышындагы иң бәхетле, иң дулкынландыргыч мизгелләрнең берсе. «Идегәй» дастанында каһарманнарның ата булу шатлыгы шактый кызыклы тасвирлана.

Әсәрдә Туктамыш ханның игезәк кызлары тугач бәби туе уздыру күренеше шулай сурәтләнә:

Туктамыштай олы хан
Аналыклар алдырып,
Сан сөяген бактырды.
Хан казнаны ачтырды,
Көрәкләп тәңкә чәчтерде,
Ханнан ханны җыйдырды,
Бидән бине җыйдырды,
Ту бияләр суйдырды.
Утыз көн уен кылдырды,
Кырык көн туен кылдырды.
(36)

Идегәй дә, улы тугач, бу шатлыклы вакыйганы зурлап билгели:

Аталыклар алдырып,
Сан сөяген бактырды.
Алтыннан чүмәк уйдырды,
Көмештән төбәк койдырды.
Кыр кураен семәк иттерде;
Кыр курае каты булыр дип,
Алтыннан семәк кылдырды.
Ту бияләр суйдырды,
Туктамышның сансыз кол —
Барын-югын җыйдырды,
Ялгызыма алкыш тисен дип,
Өлкән бер туй кылдырды.
(37)

Биредә төрки халыкларда бала туганнан соң үткәрә торган йоланың зарури рәвештә җиренә җиткереп үткәрелгән булуы чагылдырылган.

Хәзер бәби туе өчен мотлак булган кайбер моментларга тукталыйк.

II. 1. Аналыклар (аталыклар) алдыру, сан сөяген бактыру.

Беренчесе аңлашыла кебек — кыз бала тугач, тәрбияче итеп өлкән хатыннар чакырыла; ир бала тугач, — өлкән яшьтәге ирләр алына. Ә биредә телгә алынган «сан сөяген (башка бер очракта — хан сөяген) бактыру» турында әлегә кадәр ачыкланмаган.

Борынгы төркиләр шаманлык белән бәйле бер китап барлыгына ышанганнар. Әмма аны, имеш, кәҗә ашый һәм андагы бөтен мәгълүмат аның сан сөягенә күчә. Шуңа күрә дә, кәҗәнең сан сөягенә карап, кешенең үткәнен һәм киләчәген белеп була, дип уйлаганнар. Бу рәвешле күрәзәлек кылу ысулы, кайбер үзгәрешләр кичерсә дә, төрки халыклар арасында гасырлар буе яшәп килгән. Ул, хәтта, борынгы грек көтүчеләренә дә билгеле булган. Бу күрәзәлек итүнең тәртибе түбәндәгечә: гадәттә сарыкның, сирәк очракларда кәҗәнең яисә алар урынына башка бер хайванның (мәсәлән, чукчалар киекнең, кореялылар исә тюленьнең) сан сөяген алганнар. Иң мөһиме — хайван яңа суелган булырга тиеш. Сөяк кырыендагы итләрне бик зур тырышлык белән юнып алганнар һәм аны, җавап алырга теләгән сорауны уйлап, утта куырганнар. Галимнәр бу төр күрәзәчелекнең хайван тәненең үзенә җыйган көче белән бәйле булуы турында сөйлиләр[15]. Утта куырылган сан сөяге чытырдап куйса, сугышка юраганнар. Сан сөяге белән фал ачу турында Мәхмүт Кашгари сүзлегендә (XI гасыр) дә әйтелә, Рубрук язмасында (XIII гасыр) да телгә алына. Фарсы галиме һәм дәүләт эшлеклесе Рәшидетдин дә үзенең язмасында: «Аргунның авыруы турында бер фикер алу өчен, шаманнар, үзләренең кагыйдәләренә күрә, бер сан сөяген бик җентекләп тикшерделәр» — дип яза.

Монголлар сан сөяге белән күрәзәлек итүне «даллажы» дип, төрки халыклар исә «ягрынҗы» дип атаганнар. Соңгырак дәвердә бу рәвештә фал ачу Аксак Тимер Урдасында (Ибне Гарәбшаһ язганча), сәфәвиләр чорында Иранда һәм Урта Азиягә хас тормыш-көнкүрешне үзләрендә саклап калган Мисыр мәмлүкләрендә дә очрый. 1771 елда казакълар арасында сәяхәт иткән бер рус полковнигы да алар арасында сан сөяге белән күрәзәлек итү турында язып үтә[16]. Ул кыргыз халкында да күзәтелә. Мәсәлән, «Манас» дастанында Манасның дусларының берсе *төлгөчү* (фал ачучы) Кара Төлек, икенчесе исә *ягърынчы* (калак сөяге белән фал ачучы) Кара Бәдиш телгә алына. А. Инанның күзәтүенчә, Төркиянең Анатолия өлешендә калак сөяге белән фал

ачу XX гасырның 60 елларына кадәр дәвам иткән.

«Идегәй» дастанында да Туктамыш хан белән Идегәй, әти кеше буларак, балаларының киләчәге белән кызыксынып, сан сөяген бактыралар. Киләчәктән хәбәр алу теләге — кешеләргә тарихның һәр дәверендә хас булган күренеш. Калак сөяге белән багучылык итү исә татарларда элек тә киң кулланылган. Мәсәлән, халык ышанулары арасында, «утта куырылган калак сөягенең өске ягы буйга ярылса, эшең (юлың, ниятең, гыйшкың) хәерле булыр, әгәр дә инде сөякнең өске ягы иңгә ярылса — хәерсез булыр», дип фаразланган. Калак сөяге өстенә борчак сибеп ачылган фал төре дә булган, ләкин аның мәгънәсе оныtылган[17].

Дастанда «сан сөяген бактыру» диелә. Сан сөяге — гәүдә сөяге дигән мәгънәдә килә. Бу фалны «калак сөяге белән юрау» дип тә әйтә торган булганнар. «Калак» сүзенең татар телендә бер аңлатмасы «көрәк шәкелендә» дип бирелә. Димәк, сүз шул ук көрәк сөяге турында бара. Бу төр фалны ачучыларга *явырынчы* дигәннәр (явырын — арка, калак сөяге, көрәк сөяге).

«Идегәй» дастанында мәҗүси галәмәтләреннән багу гадәте еш очрый. Мәсәлән, Туктамыш хан Идегәйнең кем булуын ачыклау өчен күрәзәче Субра җырауны чакырта. Алып Кара Тиен дә үзенең кем кулыннан үләчәген багучыдан белүе турында болай сөйли:

Гүрем кайда — белмәдем,
Үлемем кемнән — белмәдем;
Бакчыдан багым бактырдым,
Фалчыдан фалым ачтырдым,
Сынчыдан сыным сынаттым,
Анда белдем бу эшне:
Мине үтергән ир булсаң —
Ул син икән, Идегәй!
(103-104)

II. 2. Тәңкә чәчү.

Килгән кунаклар өстенә алтын-көмеш тәңкәләр сибү дә борынгыдан килгән йолаларның берсе. Мәсәлән, Ибне Фазлан сәяхәтнамәсендә Болгар падишаһының аларны каршы алырга чыгуы турында «Җиңендә тәңкәләр бар иде, аларны безнең өсләребезгә чәчте» — дип яза[18].

Тәңкә, кайбер галимнәр фикеренчә, бик борынгы чорларда Тәңрегә табынуның бер символы булып торган. Бигрәк тә көмеш тәңкәгә, чөнки көмеш төс күк төсен хәтерләтә һәм борынгы гасырлардан ук Күк Тәңре белән аралашуны белдереп торган. Тәңкә чәчү гадәте, гомумән, күп кенә бәйрәмнәргә дә хас булган[19]. Дастанда, мәсәлән, Шаһ Тимер дә, кызын коткарып алып кайткан Идегәй янына чыккач шулай эшли:

Иләкләп алтын чәчтерде,
Көрәкләп көмеш чәчтерде.
(111)

Тәңкә чәчү, беренчедән, сәламләү, хуш күрү, илаһи затлардан мәрхәмәт теләү символы булса (гадәттә, сөенечтән эшләнгән), икенчедән, мул тормышны да күрсәтеп һәм теләп торгандыр дип, фаразларга мөмкин. Ә бәлки, монда тимернең магик көчкә ия булып, кара көчләрне юк итү өчен кулланылуын да искә алырга кирәктер. Мәсәлән, Р. А. Солтангәрәева язганча, нәкъ менә бу теләк белән борынгы кешеләр дә, килгән кунакның аяк киеменең үкчәсе астына тәңкә куя торган булганнар (начарлыкның кеше үкчәсендә яшәвенә ышанганнар)[20].

II. 3. Ту бияләр суйдырып туй ясау.

Дастанда бала тугач, ту бияләр суела. Күк Тәңрегә ышану системасына хас булган кебек, корбан чалу гадәте күп кенә диннәрдә дә очрый. Коръәндә Аллаһе Тәгаләнең: «Без һәр өммәт өчен корбан чалуны шаригать кануны итеп кабул кылдык», дигән сүзләре бар (Хаҗ сүрәсе, 34 аять). Мәсәлән, скифларда ат һәм сарык корбан ителгән. Күк төркиләр дә бишенче айда үткәрелгән милли һәм дини бәйрәмнәрдә Тәңрегә күп итеп ат һәм сарык корбан иткәннәр[21]. Монголларда һәм төркиләрдә борынгы гасырларда, әле ислам дине кергәнче үк, корбан итеп ат чалу киң таралган була.

Болгарларда да елга бер тапкыр Корбан көне («кан көн») үткәрелгән. Ул хәзерге чәршәмбе көненә туры килгән. Корбан ителгән хайван, гадәттә, ак яисә сары төстә һәм иң әһәмиятлесе — әле эштә кулланылмаган, колынламаган булуы шарт ителгән[22]. Монголларның иң яраткан һәм хөрмәт иткән төсләренең дә ак төс булуын әйтергә кирәк. Гомумән, ак төс байтак диннәрдә һәм халыкларда сафлык, пакълек символы булып саналган. А. Инан да ак төсле хайваннарның тәңреләр тарафыннан яратылган һәм рухларның да хушына килә торган булуы турында яза[23]. Кыргыз халкының «Манас» дастанында да Манас тугач, атасы ак бүз бия суйдыра.

Ту бия дигәндәге «ту» сүзе исә «колынламаган» мәгънәсендә килә. Колынламаган бия яшь булганга күрә аның ите дә йомшак һәм тәмле була. Идегәй Акбеләкне коткa-

рып алып кайтканнан соң да, Шаһ Тимер ту бияләр суйдырып, туй ясый. Килгән кунакка аш бирү йоласының да бик борынгы чорларга барып тоташуы мәгълүм. Болгар падишаһы, кунакларны үз көббәсенә чакырып, аларга аш әзерләтүе турында Ибне Фазлан да язып калдырган[24]. Зурдан кубып, мәҗлес-ашлар үткәрү гадәте Болгар чорында ук хас була.

Элек-электән төрки халыкларда, бала тугач, ак бияләр суелып, аш үткәрү гадәте — шатлык-сөенеч, бәхет китерсен дигән теләк белән башкарылган[25]. А. Инанның фикеренчә, төрки халыкларда корбан чалу һәм акча, яисә берәр ашый торган ризык сибү гадәте — ул Тәңре ризалыгы өчен, аннан ярдәм сорап, теләкләрнең кабул ителүе өчен дә башкарыла торган булган[26].

Ләкин дастанда Туктамыш хан белән аның хезмәтендә булган Идегәй үткәргән бәби туйларында, дәрәҗәләргә бәйле рәвештә, кайбер аермалыклар чагылыш тапкан. Игезәк кызлары тугач Туктамыш хан бәйрәмне шулай үткәрә:

Ханнан ханны җыйдырды,
Утыз көн уен кылдырды,
Кырык көн туен кылдырды.
(36)

Мондый туйны дастанда бары тик тагын бер кеше — шулай ук хөкемдар булган Шаһ Тимер генә уздыра ала. Кызы Акбеләк Кара Тиен Алыптан коткарылгач ул шундый мәҗлес оештыра:

Шаһ Тимернең сансыз кол —
Барын-югын җыйдырды,
Ту бияләр суйдырды,
Утыз көн уен кылдырды,
Кырык көн туен кылдырды.
(112)

Идегәй исә, улы Норадын тугач үткәргән бәби туе турында, болай ди:

Син туганда, Норадын,
Ту бияләр суйдырдым,
Алты көнләп аш биреп,
Галимнәрне туйдырдым,
Җиде көнләп аш биреп,
Ятимнәрне туйдырдым…
(194)

Күренгәнчә, Идегәй үз хәленә күрә туй уздыра һәм, иң әһәмиятлесе, ул анда галимнәрне дә җыярга, ятимнәрне дә сөендерергә онытмый. Биредә инде Идегәйнең кешелеклелеге белән бәйле күркәм сыйфатлары ачыклана. Нәкъ моңа охшаш момент «Манас» дастанында да бар — Манасның атасы, улы тугач, туймаганнарны туйдыра, ачларга аш бирә:

Җәнтәккә сигез бия чалган,
Туймаганны туйдырган,
Тәрбияле хайваннарны суйган,
Ач булганнарны туйдырган.

Халыкка хезмәт итү, аны олылау, сыйлау — төрки дастаннарда юмартлык чагылышы булып тора. Каһарманнарның мондый юмартлыгын «Угыз» дастанында һәм «Дәдәм Коркыт китабы»нда да күререгә мөмкин.

II. 4. Исем кушу.

Төрки халыклар арасында исем кушу — борынгыдан килә торган иң күркәм йолаларның берсе. Ул «Идегәй» дастанында җиренә җиткереп башкарыла. Мәсәлән, Туктамыш ханның үз кызларына исемнәр кушу шулай әйтелә:

Олы кызы айга тиң —
Атын куеп Ханәкә,
Көче кызы көнгә тиң —
Атын куеп Көнәкә,
Күңелен анда тындырды.
(36)

Идегәй дә улына мәгънәле исем куйдыра:

Хан каршында туды дип,
Атын Норадын куйдырды.
(37)

Борынгы йола буенча, балага исемне атасы куша. Без моны алтай дастаны «Магадай-Кара»да да күрәбез: Алтын-Тарга, баласына исем кушу өчен, иренең аудан кайтуын көтә[27]. Кайбер дастаннарда балага исемне Хызыр куя. «Идегәй» дастанында исә яңа туган кызларына исемнәрне Туктамыш хан, улына — Идегәй куша.

Исемне балага изге теләкләр теләп, зур өметләр баглап кушканнар. Бу — аерым бер әһәмияткә ия булган йола. Балага исем кушу йоласы да тамырлары белән бик борынгы чорларга барып тоташа: кешеләр әле тел яралган дәвердә үк әйбернең исеме җисеменә туры килергә тиеш дип уйлап, дөньяда һәр нәрсәгә — җансыз әйберләргә, тереклек ияләренә, кешеләргә исемне, аларның берәр үзенчәлекләреннән чыгып кушканнар[28]. Борынгы һинд чыганагында «исем — кешеләрнең тормышларындагы иң әһәмиятле нәрсәдер. Исем кешенең язмышын билгели. Исеме белән кеше шөһрәтдан казана. Шуңа күрә, исем кушу йоласы

— иң зур мактауга лаек йоладыр», диелә[29].

Гадәттә, яңа туган баланы айга, көнгә (ягъни кояшка), нурга, йолдызга тиңләгәннәр. «Идегәй» дастанында телгә алынган исемнәрнең, бөтенесе диярлек, төрки чыгышлы — Котлыкыя, Җантимер, Кобагыл, Идегәй, Туктамыш, Урман, Субра, Кара Тиен, Тимер, Норадын, Айтулы, Акбеләк, Йәникә, Ханәкә, Көнәкә, Җанбай. Хәтта гарәп теленнән кергән Кадыйр исеменә дә төрки компонент «бирде» кушылган.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Идегәй. Татар халык дастаны. – Казан, 1988. – 254 б. (Мисаллар әлеге чыганактан алынды һәм бит саннары шуннан күрсәтелә. — *Ч. З.-Ч.*).
2. Сулейманова-Валеева Г. Типология взаимодействия художественной культуры татар в системе «Восток — Запад» // Tatarica. Звездный час татарской истории. – Казань, 1997. – С. 113.
3. Jean-Paul, R. Türklerin ve Moğolların Eski Dini / Çeviren A. Kazancıgil. – İstanbul, 1998. – 2 baskı. – S. 14.
4. İnan, A. Tarihte ve Bugün Şamanizm. – Ankara, 1995. – S. 11-12.
5. Ergun, M. Alıp Manas. – Ankara, 1998. – S. 102.
6. İnan, A. Makeleler ve İncelemeler. – Ankara, 1987. – Cilt 1. – S. 140-141.
7. Õgel, B. Türk Mifolojisi. – Ankara, 1993. – Cilt 1. – S. 105.
8. Tağı, G. Kazak Türklerinde Evlenme Geleneği // Bitirme Çalışması (yayımlanmamış). – Muğla, 2004. – S. 26.
9. Баязитова Ф. Гомернең өч туе (Татар халкының гаилә йолалары). – Казан, 1992. – Б. 115.
10. Cingõz, S. M. Anadolu'nun Bazı Yõrelerinde Gerdek Sabahı Geline İlgili Adet ve Uygulamalar Üzerine Bir Atlas Denemesi // V. Villetlerarası Türk Halk Kültürü Kongresi. Gelenek Gõrenek İnançlar Seksiyon Bildiriler. – Ankara, 1997. – S. 349.
11. Султангареева Р. А. Башкирский свадебно-обрядовый фольклор. – Уфа, 1994. – С. 99.
12. Akmataliev, A. Kırgız Folkloru ve Tarühü Kaharmanlar // Atatürk Kültür Merkezi Başkanlığı Yayınları. – Ankara, 2001. – S. 79-81.
13. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. – Казан, 1979. – 2 т. – Б. 37.
14. Татар теленең аңлатмалы... – Казан, 1977. – 1 т. – Б. 33.
15. Jean-Paul, R. Türklerin ve Moğolların… – S. 74-75.
16. Ibid. – S. 75-76.
17. Татар мифлары. – Казан, 1996. – Б. 267, 269.
18. Фәхретдинов Р. Болгар вә Казан төрекләре. – Казан, 1993. – Б. 67.
19. Султангареева Р. А. Указ. соч. – С. 10, 23.
20. Там же. – С. 71.
21. Turan, O. Selçuklu Tarihi ve Türk İslam Medeniyeti. – İstanbul, 1980. – 3 baskı. – S. 401.
22. Jean-Paul, R. Türklerin ve Moğolların… – S. 194.
23. İnan, A. Tarihte ve Bugün Şamanizm… – S. 101.
24. Фәхретдинов Р. Күрс. хез. – Б. 67-68.
25. Yıldız, N. Manas Destanı ve Kırgız Kültürü ile İlgili Tespit ve Tahliller. – Ankara, 1995. – S. 252.
26. İnan, A. Eski Türk Dini Tarihi. – İstanbul, 1976. – S. 46-54.
27. Маадай-Кара. Алтайский героический эпос. – Горно-Алтайск, 1995. – С. 25.
28. Зәкиев М. Исеме җисеменә туры килсен // Саттаров Г. Ф. Татар исемнәре сүзлеге. – Казан, 1981. – Б. 3.
29. Рандей П. Б. Древнеиндийские домашние обряды. – М., 1982. – С. 87.

Чулпан Зарипова-Четин,
филология фәннәре кандидаты,
Мугла университеты доценты
(Төркия)

РЕЗЮМЕ

В статье доцента университета г. Мугла (Турция) Ч. Зариповой-Четин рассматриваются некоторые семейно-бытовые мотивы, нашедшие отражение в тексте дастана «Идегей». Они анализируются в контексте устного народного творчества отдельных современных тюркских народов.